

Рузаевка районы Мордовская Пишля авылы халкынын мәдәниятен, гореф-гадәтләрен элек-электән саклыйлар, хормәт итәләр һәм vстерәләр. Биредә туку серләрен саклаучы Федор Иванович Юдин яши. Ул, тормыш иптәше белән бергә, 2000нче елларда бу авылда йорт сатып алым яши башлый.       Федор Иванович Чамзинка районында биш балалы гаиләдә туа һәм vсә. Федор ин олкәне булганга, ата-аналарына хужалык буенча ярдәм итәргә ана туры килгән. Шул вакыт ул станокта тукырга да vзенен әбисе Устинья Павловнадан ойрәнгән. Дvрт яшьлек малай әбисе янәшәсендә басып торганда анын ничек тукуын караган. Шул вакыт һәр йортта да станок булмаган, оста куллы йортта гына булган. Анын әтисе һәм бабасы балта осталары булганнар; vз куллары белән кул астындагы материаллардан жиһазлар ясаганнар. Шулай ук туку станогын да.
Борынгы заманнардан бирле Русьтә традицион ой тукуы булды һәм ул крестьяннар тормышында моһим роль уйнады. Йорттагы һәр хатын-кыз кеч-кенәдән кием-салым, билбау, тасмалар, солгеләр, ашъяулыклар, чаршаулар, тәрәзә пәрдәләре, идәнгә тукыма жәйгечләр һәм башка әйберләр тукый белә иде. Осталар vз куллары белән файдалы гына тvгел, матур әйберләрне дә тудырырга тырышканнар.
- Һәр мордва йортында диярлек, козге һәм кышкы кичләрдә, хатын-кызлар тукый иделәр, - дип сойли Федор Иванович. - Беренче вакытта безнен гаилә әби-бабайлар йортында яшәде. Һәр кышны алар станок куйдылар. Минем очен ул бик зур тоелды. Әти белән бабай барысын да vз куллары белән ясадылар, ә мин аларга булыштым. Бер кон эчендә тәжрибәле остаз оч-дvрт метрга кадәр тукыма суга ала иде шул станокта.
Элек һәр йортта буялмаган идәндә vзебез тукыган матур коврикләр - «ватоллар» ябылды. Аларны туку алай ук авыр тvгел, ә менә полотно станокка житкәнче зур юл vтә иде. Киндерне vзебез vстердек. Коздән аны жыеп талкыда сугарга кирәк иде, аннары - тарарга, кабартырга, соныннан гына соры тосле каты киндер жеп чыга. Аны тукыганнар. Ул вакытта агарту юк иде: тукыманы суыкка чыгарып карга кvмәләр, аннары елгадагы бәкедә (прорубь) аны юалар, вальк белән - унайлы ручка белән кечкенә генә агач корәк белән ваткалыйлар. Менә мин моны яхшы хәтерлим, - дип уртаклаша Ф.И.Юдин.
Кvптән тvгел Федор Иванович жирле клубта йоз еллык иске туку станогын ремонтларга ярдәм иткән. Озак вакытлар ул музейда сvтелгән кыяфәттә торган. Мастер-балта остасы vзенен профессиональ карашы белән «агачларнын оеменә» карап, нинди частьләр житмәвен, ә нинди олешләрне алыштырырга кирәклеген билгеләде. Һәм берничә коннән борынгы станок эшли башлаган. Федор Иванович Юдин балта остасы, столяр, механик, игенче генә тvгел, бик кунакчыл кеше һәм аш-су остасы да. Анын тәмле пироглары ботен тирә-юньдә билгеле.

Шуны әйтергә телим: яшьләргә vз ата-бабаларынын халык һонәрләре турында сойли алырлык авылларда кешеләр коннән-кон азая бара. Шуна кvрә безнен буын әби - бабайларыбызнын vткәндәге осталыкларын хәтерли һәм яхшы белә торган кешеләр белән аралашып олгерергә иде.

**Н.ХӘЛИЛ**